**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

« 13 » октября 2023г. № 139

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 233 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлары турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 4 августындагы 469-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 492-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 233 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына (01.04.2022 № 54, от 01.06.2022 № 101, от 08.09.2022 № 173, от 05.10.2022 № 191, от 20.03.2023 № 56 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карарның 1.1 пункты белән расланган Җир кишәрлеген сәүдәләр үткәрмичә генә арендага, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба текст буенча - регламент):

А) 2.8.2.1 пунктының 6.2 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле пунктча белән тулыландырырга:

«о) табигый дәвалау ресурсын саклауның санитар (тау-санитария) округының беренче зонасы чикләрендә.»;

Б) Регламентка 7 номерлы кушымтаның 23 пунктында «әлеге күчемсез мөлкәт объектлары бирелгән» сүзләрен «дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге биналар, корылмалар арендага бирелгән,» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Җитәкче урынбасары – Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге башлыгы Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин